**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«02» 09 2022 ел №2483

Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә урнашкан 16:39:131202:39, 16:39:131202:30 (16:39:131202:29, 16:39:131202:28) кадастр номерлы җир кишәрлекләренең территорияне планлаштыру проектын эшли башлау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 бүлеге нигезендә, Калмия авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘ**

1. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегендә урнашкан 16:39:131202:39, 16:39:131202:30 (16:39:131202:29, 16:39:131202:28) кадастр номерлы җир кишәрлекләренең территорияне планлаштыру проектын эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, техник регламентлар таләпләре нигезендә алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин